Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге
Талкыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

5 ноябрь, 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлегенең Талкыш торак пунктында 2020 елның 5 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 33 (утыз өч).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 17 (унҗиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 17 (унҗиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2021 елда Тогашево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, 1 төркем инвалидларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Янсуар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Янсуар авыл җирлеге башлыгы В.Н. Таланов